Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.01.2022 ел Менделеевск ш. № 31

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районында
мәет җирләү буенча хезмәтләрнең
гарантияләнгән исемлеге нигезендә
күрсәтелә торган хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында»1996 елның 12 гыйнварендагы 8 номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында мәет җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хакын 6964 сум 68 тиен күләмендә 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Норматив документлар» бүлегендә урнаштырырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http//pravo.tatarstan.ru бастырырга.

3. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында мәет җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хакын раслау турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 29 гыйнварендагы 45 номерлы карарын 2022 елның 01 февраленнән үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары С.В. Метальниковка йөкләргә.

Җитәкче Р.И. Беляев

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 24 гыйнварендагы
31 номерлы карарына 1 кушымта

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районында
2022 елның 1 февраленнән
мәет җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге
хакы

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү хакы (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Мәет җирләү өчен кирәкле документлар әзерләү | 0,00 |
| 2. Мәет җирләү өчен табутны һәм башка кирәкле әйберләрне бирү һәм китерү | 2346,23 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (мәет калдыкларын) зиратка алып бару | 992,57 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3625,88 |
| барлыгы | 6964,68 |

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 24 гыйнварендагы
31 номерлы карарына 2 кушымта

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районында
2022 елның 1 февраленнән
мәет җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге
хакы

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү хакы (сумнарда) |
| --- | --- |
| 1. Мәет җирләү өчен кирәкле документлар әзерләү | 0,00 |
| 2. Гыйбадәт киеме кидерү | 122,36 |
| 3. Мәет җирләү өчен табутны һәм башка кирәкле әйберләрне бирү һәм китерү | 2223,86 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (мәет калдыкларын) зиратка алып бару | 992,57 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3625,89 |
| барлыгы | 6964,68 |